МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.08.2020 Казан ш. № 498-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2020 елның 22 гыйнварындагы № 35-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүенә бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 22 гыйнварындагы № 35-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Ф.А.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
10.08.2020 № 498-пр
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 22 гыйнварындагы № 35-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.5 подпунктның икенче абзацына «мәгълүмати стендлардагы» сүзләреннән соң «һәм Министрлыкның рәсми сайтындагы» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге (реквизитлары һәм рәсми басылу чыганаклары күрсәтелеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 14 ноябрь, 2002 ел № 161-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 161-ФЗ Федераль закон) 18 статьясында билгеләнгән очракларда күчемле милек;»;

в пункте 1.6:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис) (алга таба – МФЦның ерактагы эш урыны);»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) - «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 210-ФЗ Федераль закон) 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Гаризаларның киңәш ителгән формалары әлеге Регламентның 1, 2 кушымталарында китерелгән.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 295, 296 ст. (алга таба – РФ ГК);

№ 161-ФЗ Федераль законның 18, 20 ст.;

“Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы №7-ФЗ Федераль законның 9.2 ст.

«Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге № 174-ФЗ Федераль законның 3 ст. (алга таба – Федераль закон № 174-ФЗ);

«Татарстан Республикасы милке белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге № 35-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – ТР Законы № 35-ЗРТ)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.32, 3.3.34, 3.3.35, 3.3.36 пунктлары (алга таба – Министрлык турында нигезләмә)»;

2.2 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык турында нигезләмәнең 3.3.32, 3.3.34, 3.3.35, 3.3.36 пунктлары;

«Дәүләти (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.05.2010 № 83-ФЗ Федераль Законны Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен булдыру, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү ягыннан тәртип урнаштыру, шулай ук, Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючының һәм мөлкәт иясенең функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентацияләү ягыннан Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.10.2010 № 820 карарының 2 п. (алга таба - № 820 ТР МК карары)»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, шул исәптән, электрон формада һәм аны тапшыру тәртибе | Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне (алга таба – мөлкәт) арендага бирүне килештерү өчен зарури булган документлар:<br>1. Дәүләт мөлкәтен сатулашу уздыру юлы белән арендага бирүне килештерү турында гариза (1нче кушымта) яки дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага бирүне килештерү турында гариза (2нче кушымта).<br>2. Арендага бирү өчен тәкъдим ителә торган биналарның планнары күчермәләре һәм биналарның юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган техник паспорты нигезендә аларга эшләнгән экспликация.<br>3. Арендага бирү өчен билгеләнгән җиһазларның юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган исемлеге (арендага бирелерлек җиһаз булган очракта).<br>4. Дәүләт мөлкәтенең билгеле бер вакыт чорына аренда (аренда түләве ставкалары) бәясе турында бәйсез бәя куючының отчеты.<br>5. Мөлкәтне арендага бирүнең максатка ярашлылыгын нигезләү.<br>6. Арендага бирү өчен тәкъдим ителә торган биналар һәм бүлмәләрнең электрон форматтагы | «Конкуренцияне саклау турында» 26 июль 2006 ел № 135-ФЗ Федераль законның $17^{1}$ ст.<br>РФ ГК 607 ст;<br><br>«Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге № 135-ФЗ Федераль законның 8 ст.;<br>РФ ГК 607 ст; |

| | | |
|---|---|---|
| | фотосурәтләре.<br>**Автоном учреждениеләр өчен өстәмә:**<br>7. Автоном учреждениенең багучылар шурасының мөлкәт белән эш итү буенча алыш-биреш ясау турындагы тәкъдимнәре.<br>**Казна учреждениеләре** (күчемле мөлкәтне арендага биргәндә) **һәм бюджет учреждениеләре өчен** (бюджет учреждениеләре тарафыннан “Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль законның 9.2. статьясындагы 13 пунктында билгеләп куелган нигез билгеләренә туры килүче эре алыш-биреш, яки “Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль законның 27 статьясында билгеләп куелган нигез билгеләренә туры килгән мәнфәгатьләр булган алыш-биреш башкарылганда) **өстәмә:**<br>8. Гамәлгә куючы ризалыгы.<br>**Балалар өчен социаль инфраструктура объекты булып торучы учреждениеләр өчен өстәмә:**<br>9. Аренда килешүе нәтиҗәләренең җитәкче кул куйган учреждениене гамәлгә куючы тарафыннан килештерелгән эксперт бәяләмәсе (мәгариф учреждениеләре һәм балалар медицина учреждениеләре өчен Мәгариф буенча федераль агентлыкның 24.03.2006 ел, № 16-55-88ин/02-12 хаты белән расланган форма буенча). | №<br>ст.<br><br>ТР<br>рас<br>баш<br>орг<br>бю<br>куе<br>вәк<br>ни<br>Тат<br>хак<br>тар<br>учр<br>фу<br>баш<br>3 п<br><br>“Ро<br>хок<br>тур<br>ию |

| | | |
|---|---|---|
| | **Арендага мәдәни мирас объектларын биргән очракта өстәмә:**<br>10. Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектыннан файдаланучының сак йөкләмәсе күчермәсе. Ул түбәндәгеләр тарафыннан рәсмиләштерелә:<br>федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата – Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә контрольлек һәм күзәтчелек итү буенча һәм мәдәни мирасны саклау буенча функцияләр башкаручы федераль орган белән килешү буенча) һәм төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан;<br>җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата – муниципаль районнарның яки шәһәр округларының башкарма органнары.<br>**Дәүләт мөлкәтен сатулашулар уздырмыйча гына арендага бирүне килештергәндә өстәмә:**<br>11. Күздә тотылган Арендаторның документлары:<br>**Юридик затлар өчен:**<br>устав яки нигезләмә күчермәсе;<br>җитәкче вазыйфасына билгеләп куелу турындагы карар күчермәсе. | зак<br><br><br><br>«Ро<br>хал<br>обт<br>ядк<br>ию<br>зак |

| | | |
|---|---|---|
| | **Шәхси эшкуарлар өчен:**<br>дәүләт мөлкәтен арендага бирү турында гариза күчермәсе.<br>Документларның барлык күчермәләре бер экземплярда тапшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан раслана.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь форматта түбәндәге ысуллар белән тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән үзе (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат);<br>почта аша.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон документлар рәвешендә бирү өчен мәҗбүри шарт булып аларны электрон имза белән «Электрон имза турында» 6 апрель 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 63-ФЗ) һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзалау тора | |

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар карамагында сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

2.11 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары»;

«Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны бирү тәртибен һәм Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары хакындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны биргән өчен түләү алу һәм кайтару, түләү күләмнәрен билгеләү тәртибен раслау турында» 06.12.2016 № 901 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары»;

2.12 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы № 601 Россия Федерациясе Президенты Указының 1 п.»;

5 бүлектә:

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Гариза бирүче тарафыннан бәян ителгәннәрне раслый торган документлар (булса), яки аларның күчермәләре тапшырыла ала.».